**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Зур Кукмара авыл җирлеге муниципаль берәмлеге**

# КАРАР

**26 ноябрь, 2020 ел** **№1**

**Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Жилой Рудник авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Зур Кукмара авыл җирлеге Уставы нигезендә 2021 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2020 елның 26 ноябрендә үткәрелгән гражданнар җыенының беренче, икенче этап нәтиҗәләре буенча йомгаклау беркетмәсе төзелде:

«Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I төркем инвалидлар, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк кешеләр, 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләрдән кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Жилой Рудник авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

1. Юлларга вак таш җәю, юлларга вак таш җәеп ямап ремонтлау (ямочный ремонт), проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру.
2. Жилой Рудник авылында юлларны кардан чистарту.
3. Жилой Рудник авылында чишмәләрне төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру.
4. Урамнарны яктырту өчен энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру.
5. Сутараткыч башняларны буяу өчен буяулар сатып алу.
6. Артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 226 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 124 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен җыенда катнашкан 124 кеше тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Жилой Рудник авылында халык җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: ««Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I төркем инвалидлар, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк кешеләр, 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләрдән кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Жилой Рудник авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

1. Юлларга вак таш җәю, юлларга вак таш җәеп ямап ремонтлау (ямочный ремонт), проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру.
2. Жилой Рудник авылында юлларны кардан чистарту.
3. Жилой Рудник авылында чишмәләрне төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру.
4. Урамнарны яктырту өчен энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру.
5. Сутараткыч башняларны буяу өчен буяулар сатып алу.
6. Артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип танырга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Зур Кукмара
авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Хәнәфиев